**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» февраля 2022г. с. Тюлячи № 13

Теләче муниципаль районы мәдәният учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган (башкарыла торган) һәм Татарстан Республикасында 2022 елга бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәтләргә (эшләргә) норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 5 сентябрендәге 638 номерлы «Муниципаль учреждениеләр тарафыннан башкарыла торган һәм Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалашканда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлеген раслау турында» карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы мәдәният учреждениеләре тарафыннан 2022 елда күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләргә бирелгән норматив чыгымнарны кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының Җитәкче урынбасары вазыйфаларын башкаручы – территориаль үсеш башлыгы Б.Г. Гайнетдиновка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Кушымта

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 10 февралендәге
«13» номерлы карары белән
расланган

**Теләче муниципаль районы мәдәният учреждениеләре тарафыннан 2022 елда күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләргә бирелгән норматив чыгымнар**

| № т/б | Учреждение исеме | Хезмәт исеме | Норматив чыгымнар, сумнар | Елга хезмәт күләме | Үлчәү берәмлеге |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Музей | Музей әйберләрен, музей тупланмаларын ачык күрсәтү | 336,73 | 2600 | Берәмлекләр |
| 2. | Китапханәләр | Китапханә кулланучыларына китапханә, библиографик һәм мәгълүмати хезмәт күрсәтү | 125,63 | 105707 | Берәмлекләр |
| 3. | Клуб тибындагы учреждениеләр | Кинофильмнар күрсәтү, клублар формированиеләре һәм үзешчән халык иҗаты формированиеләре эшчәнлеген оештыру | 329,37 | 119147 | Берәмлекләр |